ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕЧЕКУРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

*422483, село Нижнее Чекурское*
*телефон: 33-1-34*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН ЧӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

*422483, Түбән Чәке авылы*
*телефон: 33-1-34*

---

с.Нижнее Чекурское

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2022 ел №16

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге территориясендә чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны яндыру урыннарына һәм ысулларына үзгәрешләр кертү турында

РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 24 октябрендәге 1885 номерлы карары нигезендә Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге территориясендә чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында» 23.03.2018 № 4 Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Башкарма комитетының карарына үзгәреш кертергә, түбәндәге редакциядә 1 пунктны бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Түбән Чәке авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан шәхси йортлар территорияләрендә, шулай ук Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге территорияләрендә ризык әзерләү өчен ачык уттан файдалану, шулай ук чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яки эшләнмәләрне яндыру тыела.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

Түбән Чәке авыл
җирлеге башлыгы О. Б. Албутов